БАВЛИНСКОГО БАСМАСЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНА

БАУЛЫ РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЛАР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

13.03.2025 ел Баулы шәһәре №296

Баулы муниципаль район Советының
2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы
карары белән расланган, Татарстан
Республикасы «Баулы муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Муниципаль берәмлекләр исемнәре турында» 2024 елның 25 декабрендәге 10/13-09/6137 номерлы хаты нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 07 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кыскартылган атамасы - «Баулы муниципаль районы».»;

6 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спортка әзерлекнең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә;

6 статьяның 1 пунктындагы 39 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«39) әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру, шул исәптән муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгать фикер алышуларын әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә оештыру һәм уздыру;»;

48 статьяның 3 пунктчасының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чараларны оештыра, шул исәптән муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгать фикер алышуларын әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә оештыра һәм үткәрә;

48 статьяның 6 пунктчасының икенче абзацында «Россия Федерациясе субъекты» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спортка әзерлекнең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыра,» сүзләрен өстәргә;

37 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктча өстәргә:

«9.1) аларга чит ил агенты статусы алу;»;

81 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Районның җирле үзидарә органнары электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге электр челтәре хуҗалыгы объектларын, территориаль челтәр оешмасын яисә Татарстан Республикасы чикләрендә гамәлдә булган территориаль челтәр оешмасын системага салучы электр челтәре оешмасы объектларын түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Баулы муниципаль районы сайтында, дәүләт теркәвенә алганнан соң, бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Баулы муниципаль район Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров